**КАРАР**

**27 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Алан авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Курса авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә 2023 елның 27 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Алан авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 800 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 400 сум күләмендә үзара салым кертү,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау;
- мотопомпа, басымлы һәм суырткыч җиңнәр, янгын сүндерү баганасы сатып алу;
- бензин генераторын сатып алу;
- электр чүкеч сатып алу;
- Алан авылында чик буе аншлагын ясау һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”"

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 89 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 46 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 46 кеше тавыш бирде;

“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә Алан авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. « Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Алан авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 800 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау;
- мотопомпа, басымлы һәм суырткыч җиңнәр, янгын сүндерү баганасы сатып алу;
- бензин генераторын сатып алу;
- электр чүкеч сатып алу;
- Алан авылында чик буе аншлагын ясау һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Алан авылы, Х. Такташ урамы, 23 йорт каршында адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина